ГЛАВА ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ с. Верхний Услон _______________

73

Урып-җыю эшләрен башкару чорына һәм 2017 елның көзге чаралары комплексына район штабын төзү турында

Урып-җыю эшләрен уңышлы оештыру һәм уздыру өчен шартларны һәм 2017 елгы чараларның көзге комплексын тәэмин итү максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Урып-җыю эшләрен һәм 2017 елның көзге комплексын уздыру чорына район штабы төзергә (1 нче кушымта).

2. Район штабына үз карары белән штаб әгъзалары арасыннан җаваплы затларны билгеләп, түбәндәге төркемнәр төзү:

- урып-җыюны һәм туңга сөрүне матди тәэмин итү төркеме;

- бөртекле культураларны җыюны транспорт белән тәэмин итү төркеме, орлыкларны җыю һәм иминият фондын булдыру, терлек азыгы әзерләү;

- үсемлекчелек продукциясен сату һәм әзерләнә торган продукциянең сыйфатын тикшереп тору төркеме;

- массакүләм мәгълүмат чараларында кадрлар белән тәэмин итү, анализлау һәм яктырту буенча төркем;

- матди һәм мораль кызыксындыру һәм аларның үтәлешен тикшереп тору чараларын эшләү төркеме;

- мөлкәтне һәм уңышны саклау, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү төркеме.

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Р.Г. Гобәйдуллинга көн саен 07.30 сәгатькә кадәр эш торышына анализ ясарга, барлыкка килгән мәсьәләләр буенча авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә ярдәм күрсәтергә һәм штаб җитәкчесенә хәбәр итәргә.

4. Тәкъдим итәргә:

4.1. Авыл җирлекләре башлыкларына, район предприятиеләре, оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә милек рәвешенә карамастан, хуҗалыклар заявкалары буенча урып-җыю эшләрендә хезмәт шартнамәләре төзеп катнашуны тәэмин итәргә;

4.2. «Татмедиа» ААҖ филиалының «Волжская Новь» газетасы редакциясе баш мөхәррире Н.З.Мөфталиевка районның агросәнәгать комплексында эшләр барышын яктырту эшен оештырырга;

4.3. Районның авыл хуҗалыгы оешмалары җитәкчеләренә:

- 6.00 сәгатьтән 20.00 сәгатькә кадәр барлык урып-җыю чорында, төшке ашка туктамыйча, кизү торуны телефон элемтәсе аша оештырырга;

- Көн саен урып-җыю эшләренең барышы һәм авыл хуҗалыгы продукциясе әзерләүнең барышы турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Югары Ослан муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә 18.00 сәгатькә кадәр җиткерергә.

- җәлеп ителгән хезмәткәрләрнең хезмәт һәм яшәү өчен тиешле шартлар тәэмин итү һәм башкарылган эш өчен үз вакытында исәп-хисап ясау.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы Гобәйдуллин Рәшит Галимҗан улына йөкләргә.

Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Башлыгының 2017 елның
№______ карарына
1 кушымта

Урып җыю эшләре һәм 2017 елгы чараларның көзге комплексы чорына район штабы составы

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Зиатдинов<br>Марат Галимҗан улы | | Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы, штаб җитәкчесе |
| 2 | Гобәйдуллин<br>Рәшит Галимҗан улы | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы, штаб җитәкчесе урынбасары (килешү буенча); |
| 3 | Кудашов<br>Андрей Анатольевич | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең җитештерү-маркетинг бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| | | Штаб әгъзалары | |
| 4 | Ганнибаев<br>Роберт Хәкимҗан улы | | Татарстан Республикасы буенча «Россельхозцентр» ФДБУ филиалы начальнигы (килешү буенча) |
| 5 | Тимиряев<br>Виктор Сергеевич | | Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| 6 | Колесова<br>Елена Евгеньевна | | Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча) |
| 7 | Авыл<br>Роман Александрович | | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Югары Ослан районындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенең финанс-икътисад бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 8 | Сибгатуллин<br>Дмитрий Ринатович | | Татарстан Республикасы Дәүләт техника күзәтчелегенең Югары Ослан муниципаль районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча) |
| 9 | Зиатдинов<br>Марат Фарукович | | «Югары Ослан район дәүләт ветеринария берләшмәсе» ДБУ начальнигы (килешү буенча) |
| 10 | Прокопьев<br>Альберт Иванович | | -<br>«Таткрахмалпатока» ААҖ генераль директоры ( элеваторның сыйдырышлылыгы -12000 тонна) ( килешү буенча) |
| 11 | Гладков<br>Сергей Николаевич | | Печищенский икмәк кабул итү пункты директоры ( складларның сыйдырышлылыгы - 12600 тонна) ( килешү буенча) |
| 12 | Садыйков<br>Әнәс Дамир улы | | Югары Ослан муниципаль районы буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге начальнигы (килешү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | буенча) |
| 13 | Абрамова<br>Людмила<br>Владимировна | | «Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы (килешү буенча) |
| 14 | Назарова<br>Марина Юрьевна | | «Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге» МКУ начальнигы (килешү буенча) |
| 15 | Хохорин<br>Олег Евгеньевич | | Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге начальнигы(килешү буенча) |
| 16 | Сәгъдиев<br>Мильямиль Таһирович | | «Югары Ослан районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча) |
| 17 | Муфталиев<br>Нусрат Заһит улы | | «Татмедиа» ААҖ филиалының «Волжская Новь» газетасы редакциясе баш мөхәррире (килешү буенча) |
| 18 | Иванов<br>Александр Якимович | | авыл хуҗалыгы пенсионеры, ТАССРның атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре |